Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

31.03.2025ел. №236

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 30 сентябрендәге 60 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

""Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында " 2024елның 28декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2021елның 30 сентябрендәге 60номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 2 бүлегендә:

1.1.1. 2.22 пунктта «контрольдә тотыла торган затлар белән хезмәттәшлексез» сүзләреннән соң «(мәҗбүри профилактик визит кысаларында белешмәләрне җыюдан, эшкәртүдән, анализлаудан һәм исәпкә алудан тыш)» сүзләрен өстәргә;

1.1.2. 2.38.1 пунктында «һәм (яисә) кулланган килеш» сүзләрен «(урынга барып тикшерүне уздырудан тыш) һәм (яисә) фотосъемкалар кулланып, » сүзләренә алмаштырырга.»;

1.1.3. 2.50 пунктының икенче абзацында «вәкаләтле орган заты» сүзләреннән соң «контроль (күзәтчелек) чарасын уздыру мөмкинлеге булмау турында акт төзегән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

1.2.Нигезләмәнең 3 бүлегенең 3.6 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Профилактик визит

3.6.1. Профилактик визит контрольдә тотыла торган зат эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча инспектор тарафыннан кисәтү әңгәмәсе рәвешендә йә «Инспектор» видео-конференция-элемтә яисә мобиль кушымтасыннан файдалану юлы белән уздырыла.

3.6.2. Профилактика визиты барышында контрольдә тотылучы зат аның эшчәнлегенә йә аның карамагындагы контроль объектларына карата куелган мәҗбүри таләпләр турында, аларның хәвеф-хәтәр категориясен киметүнең тәкъдим ителә торган ысуллары, хәвеф-хәтәр категориясен, төрләрен, эчтәлеген һәм хәвеф-хәтәрнең тиешле категориясенә кертүдән чыгып үткәрелә торган чараларның интенсивлыгы турында хәбәр итә, ә инспектор контроль объекты белән танышуны,

тикшерү объектларын хәвеф-хәтәр категориясенә кертү өчен кирәкле белешмәләр җыюны гамәлгә ашыра һәм контрольдә торучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлү дәрәҗәсен бәяли.

3.6.3. Профилактик визит контроль (күзәтчелек) органы инициативасы буенча (мәҗбүри профилактик визит) яисә контрольдә тотыла торган зат инициативасы буенча уздырыла.

3.6.4. Тикшерү объектына профилактика визитын уздыру йомгаклары буенча «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 248-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен ачык бәяләү бирелергә мөмкин.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары И.Т. Гыйниятовка йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль район Советы рәисе Н.А. Вазыйхов